37 нче санлы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «Нәникәй»

«Безнең канатлы дусларыбыз»

темасына зурлар төркемендә ана теле шөгыле

Әзерләде һәм үткәрде:
югары категорияле тәрбияче
Галиева Заря Миргарифановна

Яр Чаллы шәһәре

2018

Тема:  Безнең канатлы дусларыбыз.

Максат: Балаларның кошлар турындагы белемнәрен баету, кошларга кешеләрнең ярдәме бик әһәмиятле булуы турында кузаллау формалаштыру.

Тәрбия бурычы: балаларда мәрхәмәтлелек, ярдәмчеллек хисләре, кошларга сакчыл
караш, кайгыртучанлык тәрбияләү.

Үстерү бурычы: чагыштыру, күзәтүчәнлек, кызыксынучанлык күнекмәләрен үстерү, сөйләм телен баету.

Белем бирү бурычы: кышлаучы һәм күчмә кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү, өлкәннәр ярдәмендә җимлекләр куярга өйрәтү.

Методик алымнар һәм ысуллар:

- ИКТ, аудиоязмалар куллану;
- проблемалы ситуацияләр чишү;
- әңгәмә үткәрү;
- күрсәтмә һәм таратма әсбаплар куллану;
- халык авыз иҗаты  әсәрләрен куллану;
- түгәрәк уены уйнау.

Җиһазлау: - экран, проектор, компьютер, магнитлы такта;

- аудиоязма, сладлар;
- кышлаучы кошлар: ала карга, чәүкә, күгәрчен, саескан, песнәк, карабүрек, чыпчык,  чукыр, тукран рәсемнәре;
- "кышкы урман", "кышкы агач"  рәсеме;
- агачтан ясалган җимлек;
- пластик стаканнарга салынган җим: ак ипи, көнбагыш , тозсыз туңмай , миләш, кабак  орлыгы, карбыз орлыгы, ярма, күркә, өрәңге орлыгы,колбаса муляжы, печенье, кәнфит, кара ипи;
- кошлар турында китапчыклар.

Сүзлек эше: җим, җимлек, туңмай, орлык, ярма.

Алдан үткәрелгән эш:

- күчмә һәм кышлаучы кошлар рәсемнәрен карау.

"Нәрсә артык?", "Нәрсә юк?", "Бер сүз белән әйт", "Кошны сыйла" дидактик уеннарын уйнау;

- төрле материаллардан җимлекләрне карау, җим әзерләү;
- кошлар турында халык авыз иҗаты әсәрләре белән танышу;
- Г. Тукайның "Кышкы кич" мультфильмын карау.

Шөгыль барышы.

I. Кереш өлеш.

1. Сәламләү.

2. Психогимнастика “Хәерле көн!”

Аудиоязма “Кошлар тавышы”

(балалар түгәрәк ясап басып торалар)

Тәрбияче - Балалар, ишетәсезмениндидер тавыш килә.

Балалар - Кошлар сайрый.

Тәрбияче - Әйе, кошлар сайрый икән. Без дә бүген сезнен белән кошлар турында сөйләшербез.

II. Төп өлеш.

1.Уен “Син кайсы кош тавышын ишетттең?”

Тәрбияче - Сез ничек уйлыйсыз, кошлар кайларда сайрыйлар?

Балалар - Кошлар урманда, бакчада, скверда, паркларда сайрыйлар.

Тәрбияче - Әйе, кошлар язын, җәен матур итеп сайрыйлар, без аларны сокланып тыңлыйбыз, тавышларыннан кайсы кош сайраганын ачыклыйбыз. Әйтегез әле, сез кайсы кош тавышын ишеттегез?

Балалар - Мин күке (сыерчык, ала карга һ.б.) тавышын ишеттем.

2.Уен “Булсаң зирәк – әйт тизрәк”

(туп белән, түгәрәктә)

Тәрбияче - Һәр кошның үзенчәлеге бар. Әйдәгез, шуларны искә төшереп, “Булсаң зирәк – әйт тизрәк” уенын уйныйк әле. Кем уенны алып бара?

Балалар - Мин, мин!

Тәрбияче - Әйдә, ..., мә туп.

- Кайсы кош көне буе үз исемен кычкыра? - карга.

- Кайсы кош кыш коне бала чыгара? -  чукыр

- Озын аяклы кош - торна

- Оча торган барабанчы? - тукран

- Хат ташучы кош? - күгәрчен

- Кайсы  кош сәгате булмаса да вакытны әйтә? - күке

- Ялтыравык әйберләр яратучы кош? - саескан

- Сары түшле кош? - песнәк

- Җырчы кош? – сандугач.

- Кыш көне безгә кышларга килүче кош? - карабүрек.

Тәрбияче - Рәхмәт, балалар, бик зирәкләр үзегез, һәр кошның үзенчәлекле ягын әйтә алдыгыз. Тыныч кына урындыкларга утырыгыз.

3. Уен “Күчмә кошлар”.

Тәрбияче - Бу нәрсә?

Балалар - Бу кышкы урман.

Тәрбияче - Кышкы урман ап – ак, тып – тыныч, кошлар да сайрамый. Кая киткәннәр соң алар?

Балалар - Җылы якка киткәннәр.

Тәрбияче - Ни өчен кошлар җылы якка киткәннәр?

Балалар - Кошларга салкын, алар туңалар, өшиләр. Җирдә, агачларда кар ята. Кошлар азык таба алмыйлар.

Тәрбияче - Җылы якка киткән кошларның исемнәрен әйтегез әле.

Балалар - Кара карга, сыерчык, күке, торна, сандугач, карлыгач.

Тәрбияче - Аларны бер сүз белән ничек әйтәбез?

Балалар - Алар – күчмә кошлар.

Тәрбияче - Күчмә кошлар кайчан безгә кайталар?

Балалар - Күчмә кошлар яз килгәч кайталар.

Аудиоязма “Тукран тавышы”

4. Уен “Кышлаучы кошлар”.

Тәрбияче - Балалар, ишетәсезме, ниндидер кош тавышы килә!

Балалар - Тукран тукылдый.

Тәрбияче - Димәк, тукран җылы якка китмәгән. Ни өчен?

Балалар - Тукран – кышлаучы кош.

Тукран салкыннан курыкмый. Агачларның  кортларын ашый. Агачларны дәвалый.

Тәрбияче - Тагын кайсы кышлаучы кошларны беләсез?

Балалар - Ала карга, чәүкә, күгәрчен, чыпчык, саескан, карабүрек, тукран, песнәк, чукыр.

Тәрбияче - Балалар, чыннан да кышлаучы кошлар  җылы якка  китмәгәннәр, барысы да безнең  янда.  Алар салкыннан курыкмыйлар, азык та табалар икән.

(Тактада кышкы агачка кышлаучы кош рәсемнәре беркетелгән)

5. Уен “Кышлаучы кош турында сөйлә”.

Тәрбияче - Кышлаучы кошлар турында шигырьләр, табышмаклар, мәкальләр, санамыш, сынамышлар бар. Кем нәрсә хәтерли? Кемдә нәрсә бар?

Балалар - Миндә табышмак бар...

(Бала кошны күрсәтеп сөйли, исемен әйтә)

Карга - ворона

Миндә әйтем  бар *:*

Карга әйтә: кар- кар- кар,
Мичтә бәлеш бар,бар.
Мичтән бәлеш алыр идем,
Өйдә кунак бар, бар.

Чәүкә - галка

Миндә сынамыш  бар : Чәүкә түбәннән очса, кар явар.

Күгәрчен - голубь

Миндә табышмак бар:

Гөрли- гөрли җырлый ул,
Кызыл читек кия ул.
Күлмәкләре күгелҗем,
Татулыкны сөя ул. Бу нәрсә?

Саескан - сорока

Миндә тизәйткеч бар:

Саескан ак кофта белән кара сарафан кигән.

Чыпчык - воробей

Миндә санамыш бар:

Чар- чар, чыпчыклар,

Бирсәгез лә орчыклар.

Анда чык, монда чык,

Саубуллаш та моннан чык.

Песнәк - синица

Миндә шигырь бар:

Песнәк (Шәүкәт Галиев)

Бер песнәк килеп

Кунды куакка

Ничек эндәшим

Икән кунакка?

Күмәч салдым да!

- Песнәк, песнәк! – дим,

Курыкма бер дә,

Җиргә төш, төш! – дим.

Карабүрек - снегирь

Миндә сынамыш бар:

Карабүрекләр тәрәзә төбендә җырласа - көн җылытыр.

Миндә шигырь бар:

Бүреген кыңгыр салган да

Карабүрек сызгыра.

Нечкә итеп сызгыруда

Малайлардан уздыра.

Тукран - дятель

Миндә табышмак бар:

Җәй шакылдый бу чүкеч,

Кыш шакылдый бу чүкеч.

Ничек түзә бу чүкеч.

Чукыр - клёст

Миндә табышмак бар:

Ул кызыл төстәге кош. Балаларын кыш көне чыгара.Чыршы һәм нарат орлыкларын ашый, балаларына да шуны ашата. Күркәләрдән орлыкларны каерып алу өчен аның томшыгының аскы өлеше өскә таба борылган, ә өске өлеше - аска карап тора. Бу нәрсә?

Аудиоязма "Буран, җил тавышы"

6. Әңгәмә "Кошлар өчен җимлекләр"

Тәрбияче - Балалар, ишетәсезме, урманда һава торышы үзгәрде. Көн тагын да салкынайды.

Балалар - Салкын җил исә. Кар ява. Буран улый.

Тәрбияче - Мондый көннәрдә кышлаучы кошларга бигрәк тә авыр. Алар бик нык туңалар, азык таба алмыйлар, ачыгалар. Кошлар өчен салкынга караганда, ачлык бик куркыныч. Шуңа күрә кошлар, кешеләр янына, шәһәрләргә, авылларга киләләр. Ничек ярдәм итәргә кошларга?

Балалар - Аларны өйгә алып кереп җылытырга, ашатырга кирәк.

Тәрбияче - Без сезнең белән бу турыда мультфильм карадык. Исемен әйтегез әле.

Балалар - "Кышкы кич" мультфильмы.

Тәрбияче - Бу шигырьне кем язган?

Балалар - Бу шигырьне Г. Тукай язган.

Тәрбияче - Чынан да көчле салкыннарда кошларны ашатырга," кошлар ашханәләре" оештырырга кирәк.

Нәрсә соң ул "кошлар ашханәсе"?

Балалар - Кошлар өчен җимлекләр ул.

Тәрбияче - Җимлекләрне нәрсәләрдән ясыйлар?

Балалар - Җимлекләрне агачтан, сок, сөт тартмаларыннан, пластик шешәләрдән ясыйлар.

Тәрбияче - Әйе, җимлекләрне төрле материалдан ясарга була. Әмма агачтан ясалган җимлекләр кошлар өчен уңайлырак, куркынычсызрак, ышанычлырак була.

7. Уен "Җимлеккә җим сал"

Тәрбияче - Балалар, безнең дә җимлек бар. Ул нәрсәдән ясалган?

Балалар - Җимлек агачтан ясалган.

Тәрбияче - Җимлеккә нәрсә салабыз?

Балалар - Җимлеккә җим салабыз.

Тәрбияче - Дөрес әйтәсез, балалар. Өстәлдә – җимнәр. Әйдәгез, аларның исемнәрен әйтеп, җимлеккә салабыз.

(Өстәлдә пластик стаканнарда җимнәр: ак ипи, көнбагыш , тозсыз туңмай , миләш, кабак орлыгы, карбыз орлыгы, ярма, күркә, өрәңге орлыгы,колбаса муляжы, печенье, кәнфит, кара ипи).

Балалар - Мин җимлеккә ак ипи салам.

Тәрбияче - Колбаса , печенье, кәнфит, кара ипине нигә җимлеккә салмадыгыз?

Балалар - Алар кошлар өчен зарарлы.

Тәрбияче - Миләшне нәрсә бик ярата?

Балалар - Миләшне кызылтүш бик ярата.

Тәрбияче - Тозсыз туңмайны кайсы кош ярата?

Балалар - Тозсыз туңмайны песнәк, тукран ярата.

Тәрбияче - Чыпчык, күгәрчен нәрсә ярата?

Балалар - ярма, көнбагыш, кабак өрәңге орлыгы.

Тәрбияче - Менә җимлегебез әзер. Балалар, бик ярдәмчел үзегез.

7. Хәрәкәтле уен "Килегез, кил, кошкайлар!"

Тәрбияче - Әйдәгез, "Килегез, кил, кошкайлар!" уенын уйнап, җимлеккә кошларны чакырыйк инде.

Уен (түгәрәктә уйнала)

Килегез, кил, кошкайлар,

Сез бит безнең дускайлар.

Чыпчык, чыпчык-чык-чырык!

Җим сиптем, кил тиз очып!

Песнәк,песнәк, кил тизрәк-

Җим сибәм сиңа әзрәк!

Чәүкә,чәүкә, кил, чәүкә-

Җим бирәм бер тәлинкә!

Күгәрченем гөр-гөр-гөр –

Җим сиптем, менә күр, күр!

Карга, карга,син кара,

Кабып кал,азык барда!

Саескан- ала канат,

Җим сибәм кабат-кабат!

Карабүрек, тукраннар,

Чукырны да алыгыз,

Җимлеккә сез куныгыз,

Көн дә кунак булыгыз!

Тәрбияче - Балалар, җимлегебезне тәрбияче апагыз белән урамга чыккач, агачка эләрсез, кайсы кошларның кунакка килгәнен күзәтерсез, җимлекне чистартып, җим салып торырсыз. Җимлеккә кайсы кошлар килде икән, киләсе шөгыльдә шул турыда сөйләшербез.

III. Йомгаклау өлеше.

Тәрбияче - Менә шөгылебез ахырына да якынлашты.

- Сез нинди яхшылык эшләдегез? Нәрсәләргә, ничек  ярдәм иттегез?

Балалар - Кошларга ярдәм иттек.

- Кошларга җимлек әзерләдек.

- Җимлеккә җимнәр салдык.

- Кышлаучы кошларны җимлеккә ашарга чакырдык.

Тәрбияче - Кошлар, аларга ярдәм итү турында кемгә сөйләячәксез?

Тәрбияче - Сез ничек уйлыйсыз, шөгыльдә алган белемнәр сезгә кайда кирәк булачак?

Балалар - Башка балаларны, әти -әниләрне кошларга ярдәм итәргә чакырганда кирәк булачак.

- Кошларга җим әзерләгәндә кирәк булачак.

- Җимлек ясаганда кирәк булачак.

Тәрбияче - Балалар, сез бик ярдәмчел, мәрхәмәтле. Тырышып эшләдегез, дөрес, матур җаваплпр бирдегез. Мин бик шатландым. Шөгыльдә алган белемнәрегез онытылмасын өчен, мин сезгә кошлар турында китапчык бүләк итәм. Шуның белән шөгылебез тәмам. Рәхмәт сезгә!

Балалар - Сезгә дә рәхмәт!

Тәрбияче - Сау булыгыз, балалар.

Балалар - Сау булыгыз!

Список литературы:

1. “Балалар бакчасында рус һәм башка милләт балаларына татар теле өйрәтү программасы” /З.М.Зарипова, Р.Г.Кидрячева, Р.С. Исаева һ.б. – Казань, 2013;

2. “Татарча сөйләшәбез”. Методик кулланмалар: 5-6, 6-7 яшь / З.М.Зарипова, Р.Г.Кидрячева, Р.С. Исаева һ.б. – Казань, Хәтер, 2011, 2012.

3. Региональная программа дошкольного образования. Төбәкнең мәктәпкәчә белеем бирү программасы / Р.К.Шаехова – Казань, 2012;

4. Федеральный закон от 29.12.2012 N 273-ФЗ (ред.от 23.07.2013) “Об образовании в Российской Федерации”.